<table>
<tr>
<td>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ</td>
<td></td>
<td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЕЛАУР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ</td>
</tr>
</table>

ПОСТАНОВЛЕНИЕ .Елаур ав. КАРАР

«23» ноябрь 2020 ел № 10

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 3 декабрендә 13 сәг.00 минутка Октябрина п., Садовая урамы 5нче йорт адресы буенча Садовая ур., 1-38 йортта яшәүчеләр, Полевая урамы 2-29 йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә.

2. Утвердить вопросы, выносимый на сход граждан:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 4000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслеген күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре).

Октябрина т.п. су алу өчен пирс әзерләү ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Октябрина п. торак пунктында гражданнар Җыенын 2020 елның 6 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2020 ел, 6 ноябрь, 2 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Октябрина авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы В.В.Охототникова